**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Какре-Елгинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

423320, Азнакаевский район,
с.Какре-Елга, ул.Советская, д.22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Кәкре-Елга авыл җирлеге башкарма комитеты**

423320, Азнакай районы,
Кәкре-Елга авылы, Совет урамы, 22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23 » март 2021 ел № 5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыю турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 олеше, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенец 2020 елның 12 маендагы № 13-20р күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның күпләп ял итүе һәм суда коткару чаралары өчен җиһазландырылган урыннар булмау сәбәпле, су объектларының һәм елгаларының санитария-гигиена нормаларына туры килмәве, елгаларда һәм сулыкларда бәхетсезлек очракларының иминлеген тәэмин итү, кисәтү һәм санын киметү максатыннан Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыярга.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең барлык милек рәвешләрендәге предприятие, оешма, учреждениеләр җитәкчеләренә су объектларында су коенуны тыю турындагы әлеге карар белән танышуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына су объектлары янында су коенуны тыю турындагы мәгълүмат белән кисәтү аншлаглары урнаштырырга.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб -адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының мәгълүмат сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

Башлык И.М.Мөхәмәтҗанов